**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» Указына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасында даими нигездә дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәтенә түләүне камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» 2006 елның 27 мартындагы ПУ-122 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 29 декабрендәге ПУ-597 номерлы, 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-538 номерлы, 2008 елның 28 апрелендәге ПУ-168 номерлы, 2010 елның 6 маендагы ПУ-295 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-461 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 21 апрелендәге ПУ-230 номерлы, 2011 елның 6 августындагы ПУ-480 номерлы, 2013 елның 2 августындагы ПУ-705 номерлы, 2013 елның 22 октябрендәге ПУ-1031 номерлы, 2014 елның 10 апрелендәге ПУ-348 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы һәм 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы министрына айлык акчалата бүләкләүне 39 000 сум күләмендә билгеләргә.»;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга айлык акчалата бүләкләү түләргә:

1) Татарстан Республикасы Президенты – 2,084 айлык акчалата бүләкләү күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры – 2,02 айлык акчалата бүләкләү күләмендә;

3) Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары,

Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе – 1,892 айлык акчалата бүләкләү күләмендә;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Россия Федерациясендә Татарстан Республикасы вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы министры – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы әгъзасы – 1,763 айлык акчалата бүләкләү күләмендә;

5) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты рәисе, Татарстан Республикасы министры, Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты рәисе, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы – 1,96 айлык акчалата бүләкләү күләмендә;

6) Татарстан Республикасы Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – 1,57 айлык акчалата бүләкләү күләмендә;

7) Татарстан Республикасы Дәүләт советының даими һөнәри нигездә эшләүче депутаты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятнең башка органнары җитәкчесе - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзасы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе секретаре – 1,51 айлык акчалата бүләкләү күләмендә».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 07 апрель
№ ПУ-295